**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**
**«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Элмәле авыл җирлегенең Иске Элмәле торак пунктында**
**2026 елда үзара салым кертү турында»**

**№ 2** **16.10.2025 ел**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең Иске Элмәле торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2026 елда муниципаль районның Яңа Элмәле авыл җирлегенең Иске Элмәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым **кертергә** көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Иске Элмәле торак пунктында; мотоблок сатып алу, мотоблок өчен асма һәм тагылма җайланмалар сатып алу; триммерлар, триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү; трактор өчен ягулык-майлау материаллары, асма һәм тагылма җайланмалар һәм запас частьләр сатып алу; агач кисү, хезмәт хакы түләү, кирәкле кораллар, материаллар сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен махсус техника яллау; генераторлар сатып алу;)
- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Иске Элмәле торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);
- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Иске Элмәле торак пунктында вак таш сатып алу, урам-юл челтәрен салу һәм чокырларны ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

**- каты коммуналь калдыкларны туплау мэйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү** (бункерлар сатып алу).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгы** **И.М. Җамалтдинов**